РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
ЭНТУГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯНТУГАН
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

27.09.2021г. № 27-1

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Янтуган авыл җирлеге территориясендә
зиратларны карап тоту кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Буа муниципаль районыны Янтуган авыл җилеге Советының «Буа муниципаль районының Янтуган авыл җирлеге территориясендә зиратларны карап тоту кагыйдәләре турында» 2012 елның 30 маендагы 1-21 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районының Янтуган авыл җирлеге территориясендә зиратларны карап тоту кагыйдәләренә (алга таба - Кагыйдә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1.1 пункт:

үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 1.1. пункты. Җирләү урыннары булып, этик, санитар һәм экологик таләпләр нигезендә, аларда үлгән кешеләрнең мәетләрен (җәсәдләрен) күмү өчен корылган җир кишәрлекләре, үлгән кешеләрнең җәсәдләрен (җәсәдләрен) яндырганнан соң мәетләрне (җәсәдләрне) күмү өчен кайгы диварлары, үлгән кешеләрнең мәетләрен (җәсәдләрен) утка тапшыру өчен крематорийлар, шулай ук мәетләрне җирләү өчен билгеләнгән башка биналар һәм корылмалар тора. Җирләү урыннары мәдәни-тарихи әһәмияткә ия булган объектларга карый ала.»;

1.2.Кагыйдә тексты:

«зират» сүзен «җирләү урыннарын» сүзе белән алмаштырырга;

1.3. 2.2 пункты:

«…,кагыйдә буларак …» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4. 2.4 пункты:

«…,кагыйдә буларак …» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.5. 5.3 пункты Кагыйдәләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Янтуган авыл җирлеге башлыгы Р.А. Җамалтдинов